**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2017 елның 11 августындагы ПУ-698 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мобилизация әзерлеге һәм махсус программалар идарәсе башлыгы;»;

б) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы шәһәр округы башкарма комитеты район администрациясе башлыгы урынбасары;»;

дүртенче – сигезенче абзацларны тиешенчә бишенче – тугызынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 09 февраль
№ ПУ-93